ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.10.2022**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2765**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 506 номерлы карарындагы үзгәрешләре белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләргә,кушымтада каралганча, үзгәрешләр кертергә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
18.10.2022ел № 2765

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. VI бүлекнең 14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«14.3. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы "Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында"гы Указы белән билгеләнгән, гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә»;
1.2. VIII бүлектә:
5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерендагы түләүләр гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә»;
6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерендагы түләүләр, гомуми белем бирү оешмасының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен квартал саен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүнең чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә».

2. «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2.1.V бүлекнең 13.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«13.3. "Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында" Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче

хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда мәктәпкәчә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә»;
2.2. VII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерендагы түләүләр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ел йомгаклары буенча мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен ай саен гамәлгә ашырылырга мөмкин»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерендагы түләүләр җитәкче урынбасарларына, мәктәпкәчә белем бирү оешмасының баш бухгалтерына, эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен квартал саен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүнең иң чик дәрәҗәсе мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә».

3. «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
3.1.VI бүлекнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы «2012 - 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең милли стратегиясе турында» Указы белән билгеләнгән, өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча, чаралар булганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә»;
3.2. VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру

характерендагы түләүләр, эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен квартал саен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенең стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә».